**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 декабрендәге 4452 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 28 маендагы 2214 номерлы**
**«Коляскадагы инвалидлар өчен махсуслаштырылган**
**торак комплексы турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Коляскадагы инвалидларның торак мәсьәләсен хәл итү максатыннан һәм коляскадагы инвалидлар өчен махсуслаштырылган торак комплексында торак урыннар бирү буенча шәһәр комиссиясе (алга таба – шәһәр комиссиясе) составына үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 28 маендагы 2214 номерлы «Коляскадагы инвалидлар өчен махсуслаштырылган торак комплексы турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 26 апрелендәге 1491 номерлы, 2021 елның 26 ноябрендәге 3104 номерлы, 2023 елның 31 маендагы 1520 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3411 номерлы, 2024 елның 27 августындагы 3575 номерлы, 2025 елның 31 июлендәге 2499 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. комиссия составыннан Е.Н.Смагинаны, Ю.Б.Трифонованы, Г.Р.Мөхәммәтшинаны, Р.Г.Фәтхуллинаны чыгарырга;

1.2. комиссия составына аның әгъзалары сыйфатында түбәндәгеләрне кертергә:

- Митрошенкова Елена Сергеевна, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе башлыгы урынбасары;

- Смагина Елена Николаевна, Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак сәясәте идарәсенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы;

- Смирнова Ирина Петровна, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башлыгы;

- Шаһвәлиева Эльмира Шаһинур кызы, Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан Республикасы оешмасы рәисе вазифаларын башкаручы (килешү буенча).

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**